| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

16.10.2019 Баулы шәһәре № 117

Баулы шәһәр Советының
«Җир салымы турында»гы
2014 елның 11 ноябрендә кабул
ителгән 114нче карарына
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында»гы 2019 елның 29 сентябрендә кабул ителгән 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Баулы шәһәр Советының «Җир салымы турында»гы 2014 елның 11 ноябрендә кабул ителгән 114нче карарына (Баулы шәһәр Советының 2016 елның 28 сентябрендәге 43нче, 2017 елның 15 июнендәге 53нче, 2017 елның 25 октябрендәге 61нче, 2017 елның 15 декабрендәге 67нче, 2018 елның 31 августындагы 81нче, 2019 елның 27 мартындагы 105нче, 2019 елның 20 маендагы 108нче карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктның 2нче пунктчасында “Торак төзелеше өчен” сүзләреннән соң (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылучы, шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Баулы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, ләкин Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да соң гына үз көченә керә.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы Рәисе Р.Х. Гатиятуллин

АППАРАТ СОВЕТА
СОВЕТ АППАРАТЫ